**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 25 май № 352

г. Казань

Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыру бердәм системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасының маршрут челтәренә кертелгән муниципальара даими йөртү маршрутлары буенча пассажирларны, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган мәктәп автобуслары маршрутлары паспортлары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар, өстәмә белем бирү оешмалары һәм физкультура-спорт оешмалары укучыларын автобусларда йөртү куркынычсызлыгын арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыру бердәм системасы турындагы нигезләмәне расларга.

2. «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесен, аңа Татарстан Республикасының маршрут челтәренә кертелгән муниципальара даими йөртү маршрутлары буенча пассажирларны, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган мәктәп автобуслары маршрутлары паспортлары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар, өстәмә белем бирү оешмалары һәм физкультура-спорт оешмалары укучыларын йөртүне гамәлгә ашыра торган автобуслар хәрәкәте мониторингын тәэмин итү өлешендә вәкаләтләр биреп, Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыру бердәм системасы операторы итеп билгеләргә.

3. «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Төбәк автоматлаштырылган мәгълүмат-идарә системасы дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесен, аңа Татарстан Республикасының маршрут челтәренә кертелгән муниципальара даими йөртү маршрутлары буенча пассажирларны, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган мәктәп автобуслары маршрутлары паспортлары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар, өстәмә белем бирү оешмалары һәм физкультура-спорт оешмалары укучыларын йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны диспетчерлаштыруны тәэмин итү өлешендә вәкаләтләр биреп, диспетчерлык үзәге итеп билгеләргә.

4. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә транспорт чаралары мониторингы бердәм системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 ел, 2 август, 661 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә эшли торган Татарстан Республикасы төбәк навигация-мәгълүмат системасын оештыру турында» 2013 ел, 27 февраль, 135 нче карарының 5 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә транспорт чаралары мониторингы бердәм системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 ел, 2 август, 661 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 24 май, 350 нче карары.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\352.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 25 май, 352 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасында
«ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә
пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыру бердәм системасы турында

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы территориясендә «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыруны тәэмин итүдә катнашкан, шул исәптән штаттан тыш хәлләр килеп чыкканда, дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар арасындагы хезмәттәшлек итү тәртибен билгели.

Бу Нигезләмә Татарстан Республикасының маршрут челтәренә кертелгән муниципальара даими йөртү маршрутлары буенча пассажирларны, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган мәктәп автобуслары маршрутлары паспортлары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар, өстәмә белем бирү оешмалары һәм физкультура-спорт оешмалары укучыларын автобусларда йөртү куркынычсызлыгын арттыру, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә ГЛОНАСС/GPS спутник навигациясе аппаратурасы аша әлеге транспорт чаралары белән идарә итү, аларны яраштыру һәм тикшерүдә тоту процессында катнашучыларның гамәлләрен регламентлаштыру һәм штаттан тыш хәлләр килеп чыкканда үз вакытында чаралар күрүне оештыру максатларында эшләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр файдаланыла:

Система – Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыру бердәм системасы;

web-интерфейс – Системаның автоматлаштырылган эш урынының махсуслаштырылган программалы тәэмин итүе, һәм ул билгеле бурычларны тулы күләмдә үтәү өчен кирәкле функционалы булган шәхси кабинеттан гыйбарәт;

йөртүче – Татарстан Республикасының маршрут челтәренә кертелгән муниципальара даими йөртү маршрутлары буенча пассажирларны автобусларда йөртү шартнамәсе нигезендә пассажирны йөртү, багажны билгеләнгән пунктка илтү һәм багажны аны алырга хокукы булган затка тапшыру йөкләмәсен үз өстенә алган юридик зат, индивидуаль эшмәкәр;

балаларны йөртә торган автобуслар – билгеләнгән тәртиптә расланган мәктәп автобуслары маршрутлары паспортлары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар, өстәмә белем бирү оешмалары һәм физкультура-спорт оешмалары укучыларын йөртә торган транспорт чаралары;

муниципальара маршрутлар автобуслары – Татарстан Республикасының маршрут челтәренә кертелгән муниципальара даими йөртү маршрутлары буенча пассажирларны йөртә торган транспорт чаралары;

автобусларны мониторинглау – спутник навигациясе системалары, кәрәзле һәм/яки радиоэлемтә җиһазлары һәм технологияләре, исәпләү техникасы һәм санлы карталар нигезендә төзелгән балаларны йөртә торган автобусларны һәм муниципальара маршрутлар автобусларын күзәтү системасы;

автобусларны диспетчерлаштыру – автобус һәм диспетчерлык үзәге арасында оператив рәвештә мәгълүмат алышуны кулланып, балаларны йөртә торган автобусларны һәм муниципальара маршрутлар автобусларын оператив үзәкләштерелгән тикшерүдә тоту һәм дистанцион идарә итү процессы;

абонент терминалы – ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS спутник навигациясе аппаратурасы;

Система операторы – Системаны үстерү, тәэмин итү һәм аның эшләү мөмкинлеге өчен җаваплы оешма;

диспетчерлык үзәге – Системаны кулланып, пассажирларны йөртүне тикшерүдә тоту буенча тәүлек буе эшли торган кизү диспетчерлык хезмәте;

ашыгыч хезмәтләр – «112» ашыгыч чакырулар хезмәте, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының Бердәм кизү диспетчерлык хезмәте, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының кизү часте, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең кизү часте, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының ашыгыч медицина ярдәме станциясе;

үзара хезмәттәшлектә катнашучылар – балаларны йөртә торган автобусларны һәм муниципальара маршрутлар автобусларын мониторинглау һәм диспетчерлаштыруны тәэмин итүдә катнашучы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар:

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

Транспорт өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча дәүләт автомобиль юлында күзәтчелек идарәсе;

җирле үзидарә органнары;

Система операторы;

диспетчерлык үзәге;

йөртүчеләр.

## 2. Хезмәттәшлек итүдә катнашучыларның вазыйфалары

2.1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы түбәндәгеләрне бирә:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына Системадан файдалана алу мөмкинлеген, шулай ук муниципальара маршрутлар автобусларын һәм балаларны йөртә торган автобусларны мониторинглау буенча контроль функцияләрен башкарырга мөмкинлек биргән функционал белән web-интерфейс;

диспетчерлык үзәгенә Системадан файдалана алу мөмкинлеген, шулай ук линиядәге күчмә состав белән идарә итү (автобусларны диспетчерлаштыру) функцияләрен башкарырга мөмкинлек биргән функционал белән web-интерфейс;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Системадан файдалана алу мөмкинлеген, шулай ук балаларны йөртә торган автобусларны мониторинглау буенча контроль функцияләрен башкарырга һәм автобуслардан файдалану буенча кирәкле хисаплылык формалаштырырга мөмкинлек биргән функционал белән web-интерфейс;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Системадан файдалана алу мөмкинлеген, шулай ук муниципальара маршрутлар автобусларыннан һәм балаларны йөртә торган автобуслардан файдалануга бәйле бозулар буенча кирәкле хисаплылык формалаштырырга мөмкинлек биргән функционал белән web-интерфейс;

Транспорт өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча дәүләт автомобиль юлында күзәтчелек идарәсенә Системадан файдалана алу мөмкинлеген, шулай ук кирәкле хисаплылыкны формалаштырырга мөмкинлек биргән функционал белән web-интерфейс;

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарында балаларны йөртә торган автобуслар мониторингы өчен җаваплы хезмәткәрләргә Системадан файдалана алу мөмкинлеген, шулай ук автобусларны мониторинглау буенча контроль функцияләрен башкарырга һәм балаларны йөртә торган автобуслардан файдалану буенча кирәкле хисаплылык формалаштырырга мөмкинлек биргән функционал белән web-интерфейс.

2.2. Система операторы:

ике көн эчендә муниципальара маршрутлар автобусларында һәм балаларны йөртә торган автобусларда урнаштырылган абонент терминалларын әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада китерелгән форма нигезендә төзелгән җирле үзидарә органы яки йөртүче гаризасы буенча Система серверына тоташтыруны оештыра;

йөртүченең муниципальара маршрутлар автобусларын һәм җирле үзидарә органнарының балаларны йөртә торган автобусларын мониторинглау өчен җаваплы хезмәткәрләргә транспортны Системага тоташтыру тәртибен җиткерә;

Системада барлыкка килә торган, муниципальара маршрутлар автобусларын һәм балаларны йөртә торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыруга

комачаулаган тоткарлыкларга каршы чаралар күрә: диспетчерлаштыруга комачаулык тудырган җитди тоткарлыклар булганда – хезмәттәшлек итүдә катнашучы мөрәҗәгатен алганнан соң ике сәгатьтән дә соңга калмыйча, Системада хисаплылык формалаштыруга бәйле тоткарлыклар булганда – 24 сәгатьтән дә соңга калмыйча;

диспетчерлык үзәге хезмәткәрләрен Системадан файдалану тәртибенә өйрәтә;

балаларны йөртә торган автобусларны диспетчерлаштыру һәм мониторинглау функцияләрен башкару өчен кирәкле мәгълүматны хезмәттәшлек итүдә катнашучылар мөрәҗәгатен алганнан соң 24 сәгатьтән артмаган вакыт эчендә Системага кертү эшләрен оештыра;

консультация ярдәме һәм техник ярдәм күрсәтү буенча тәүлек буе эшли торган телефон линиясе элемтәсен оештыра;

электрон адреска Системаның эшләмәве турында заявкалар кабул итү мөмкинлеген оешыра.

2.3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы:

министрлыкның балаларны йөртә торган автобусларны мониторинглау эше өчен җаваплы хезмәткәрен билгеләүне тәэмин итә;

автобусларны мониторинглау һәм балаларны йөртүне оештыру өчен җаваплы хезмәткәрләр билгеләү ихтыяҗы турында җирле үзидарә органнарына хәбәр итә;

ел саен, 15 августка кадәр, балаларны йөртә торган автобуслар хәрәкәте расписаниеләрен һәм паспортларын җыюны тәэмин итә;

автобусларны мониторинглау һәм балаларны йөртүне оештыру өчен җаваплы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләреннән Балаларны йөртә торган автобуслар системасына тоташтыруга гаризалар кабул итүне тәэмин итә;

балаларны йөртә торган автобусларда куелган абонент терминалларын техник тәэмин итү һәм ремонтлау, Балаларны йөртә торган автобуслар системасыннан мониторинглау һәм диспетчерлаштыру өчен файдалана алу мөмкинлеген, кисәтү төймәсенең һәм йөртүче кабинасы белән тавышлы элемтә аппаратурасының төзеклеген тәэмин итү кирәклеге турында җирле үзидарә органнарына хәбәр итә;

Система операторына Системага кертү өчен җирле үзидарә органнарыннан алынган балаларны йөртә торган автобуслар турында мәгълүмат җибәрә;

бер көн эчендә диспетчерлык үзәгенә Системага кертү өчен кирәкле балаларны йөртә торган автобуслар хакында, укучыларны йөртүне оештыру өчен җаваплы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар, өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләрен, автобуслар йөртүчеләрне алыштыру турында һәм алар белән элемтә өчен мәгълүмат җибәрә;

хезмәттәшлек итүдә катнашучыларга Балаларны йөртә торган автобуслар системасыннан мониторинглау һәм диспетчерлаштыру өчен файдалана алмау сәбәпләре хакында хәбәр итә;

мәктәп автобуслары маршрутлары паспортларын килештергәндә Балаларны йөртә торган автобуслар системасыннан мониторинглау һәм диспетчерлаштыру өчен файдалана алу мөмкинлеген исәпкә ала.

2.4. Җирле үзидарә органнары:

Балаларны йөртә торган автобуслар системасыннан мониторинглау һәм диспетчерлаштыру өчен файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итә;

Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS системасы навигация сигналлары кулланылып эшли торган,

коммерция максатларында ташулар өчен файдаланыла торган M категорияле һәм куркыныч йөкләрне ташу өчен файдаланыла торган N категорияле транспорт чараларына куелырга тиеш булган навигация чараларына таләпләрне раслау турында» 2012 ел, 31 июль, 285 нче боерыгы нигезендә балаларны йөртә торган автобусларда куелган абонент терминалларын техник тәэмин итү һәм ремонтлауны, кисәтү төймәсенең һәм йөртүче кабинасы белән тавышлы элемтә аппаратурасының төзеклеген тәэмин итә;

муниципаль районда, шәһәр округында автобусларны мониторинглау һәм балаларны йөртүне оештыру өчен җаваплы хезмәткәрне билгели;

ел саен, 13 августка кадәр, мәктәп автобуслары маршрутлары паспортларын һәм хәрәкәт расписаниеләрен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына тапшыруны тәэмин итә;

биш көн эчендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар, өстәмә белем бирү оешмалары һәм физкультура-спорт оешмалары җитәкчеләренең, балаларны йөртә торган автобуслар йөртүчеләренең, монтаж һәм транспорт оешмаларының элемтә өчен мәгълүматлары үзгәрү турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына һәм диспетчерлык үзәгенә мәгълүмат кертүне тәэмин итә;

көн саен, иртәнге сәгать 8:00гә кадәр, балаларны йөртә торган автобусның маршрутка фактта чыгуы/чыкмавы хакында Системаның web-интерфейсы аша мәгълүмат кертүне тәэмин итә;

балаларны йөртә торган автобусларның маршрутка планнан тыш чыгулары турында һәм паспорттагы маршруттан тыш рейсларга чыгу планнары хакында чыкканга кадәр өч тәүлектән дә соңга калмыйча мәгълүмат кертүне тәэмин итә;

йөртүчеләр составына тизлек режимын бозулар, маршрут паспортыннан һәм хәрәкәт расписаниесеннән тайпылу рөхсәт ителмәгәнлеге турында, шулай ук гадәттән тыш хәлләр булганда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре хакында хәбәр итүне тәэмин итә.

2.5. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы:

министрлыкның балаларны йөртүне оештыру һәм автобусларны мониторинглау өчен җаваплы хезмәткәрен билгеләүне тәэмин итә;

балаларны йөртүне оештыру өчен җаваплы хезмәткәрләрне билгеләү ихтыяҗы турында җирле үзидарә органнарына хәбәр итә;

өстәмә белем бирү оешмаларының һәм физкультура-спорт оешмаларының балаларны йөртә торган автобусларда куелган абонент терминалларын техник тәэмин итүен һәм ремонтлавын, Балаларны йөртә торган автобуслар системасыннан мониторинглау һәм диспетчерлаштыру өчен файдалана алу мөмкинлеген, кисәтү төймәсенең һәм йөртүче кабинасы белән тавышлы элемтә аппаратурасының төзеклеген тәэмин итүен үтәүләрен тикшерүдә тота;

йөртүләрне оештыру өчен җаваплы хезмәткәрләр, муниципаль районнарда, шәһәр округларында укучылар, өстәмә белем бирү оешмалары һәм физкультура-спорт оешмалары, абонент терминалларына һәм транспортка хезмәт күрсәтү оешмалары җитәкчеләре, автобуслар йөртүчеләре һәм алар белән элемтә өчен

мәгълүматлар алышуы турында җирле үзидарә органнарыннан белешмә алган вакыттан соң биш көн эчендә диспетчерлык үзәгенә мәгълүмат җибәрә;

балаларны йөртә торган автобусларның планлаштырылган барулары турында планлаштырып юлга чыкканга кадәр өч көннән дә соңга калмыйча диспетчерлык үзәгенә мәгълүмат кертергә кирәклеге хакында өстәмә белем бирү оешмаларына һәм физкультура-спорт оешмаларына хәбәр итә;

балаларны йөртә торган автобусларны оештыруда һәм тикшерүдә катнаша торган хезмәттәшлек итүдә катнашучыларга автобусны мониторинглау һәм диспетчерлаштыру өчен Системадан файдалана алмау сәбәпләре турында хәбәр итә.

2.6. Диспетчерлык үзәге:

1) балаларны йөртә торган автобусларны диспетчерлаштырганда:

функцияләрне тулысынча башкару өчен кирәкле күләмдә диспетчерлык составының эшен оештыра;

Системада реаль вакыт режимында балаларны йөртә торган автобусларны диспетчерлаштыруны әлеге төр хезмәтләр күрсәтүгә финанслау лимитлары кысаларында оештыра;

Системадан алынган мәгълүматлар нигезендә балаларны йөртә торган автобуслар йөртүчеләрнең тизлек режимын, расланган хәрәкәт расписаниесе һәм маршрутын саклавын һәм бозуларга үз вакытында чаралар күрүен тикшерүдә тота;

транспорт чарасы кабинасы белән – тавышлы элемтә, шулай ук йөртүче белән телефон элемтәсе аша балаларны йөртә торган автобуслар йөртүчеләре белән үзара бәйләнештә тора;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар, өстәмә белем бирү оешмалары һәм физкультура-спорт оешмалары җитәкчеләре һәм җирле үзидарә органнарында балаларны йөртүне оештыру өчен җаваплы затлар белән телефон элемтәсе аша үзара бәйләнештә тора;

һәр елның 1 сентябренә кадәр яисә хезмәттәшлек итүдә катнашучылардан барлыкка килгән үзгәрешләр турында мәгълүмат алганнан соң 24 сәгать дәвамында Системага балаларны йөртә торган автобуслар хәрәкәте расписаниеләрен һәм аларның маршрутларын кертүне тәэмин итә;

балаларны йөртә торган автобуслар белән идарә итү буенча нәтиҗәле эш оештыру өчен кирәкле белешмә мәгълүматлар базасын төзи (автобуслар йөртүчеләр, транспорт чарасын линиягә чыгару өчен җаваплы затлар, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар, өстәмә белем бирү оешмалары һәм физкультура-спорт оешмалары җитәкчеләре турында, транспорт чараларына һәм автобусларда, транспорт дислокациясе урыннарында куелган абонент терминалларына техник хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыра торган оешмалар хакында элемтә өчен мәгълүмат һ.б.);

сменадагы эш һәм хәлләр турында оператив белешмәләр һәм рапортлар төзи, йөртү куркынычсызлыгын оештыруда һәм башкарыла торган эш нәтиҗәлелеген бәяләүдә катнаша торган хезмәттәшлек итүдә катнашучылар өчен кирәкле хисаплылылык әзерли;

йөртүчеләрдән һәм балаларны йөртүне гамәлгә ашыруда катнаша торган башка затлардан шалтыратулар кабул итү буенча тәүлек буе эшли торган «кайнар линия» оештыра;

электрон почта аша хезмәттәшлек итүдә катнашучылардан балаларны йөртә торган автобуслар турында мәгълүматлар, хәрәкәт маршрутларында һәм расписаниеләрендә барлыкка килгән үзгәрешләр хакында һәм элемтә өчен мәгълүматлар кабул итүне оештыра;

балаларны йөртә торган автобуслар белән гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракларда, әлеге Нигезләмәнең 4 бүлегендә күздә тотылган тәртиптә ашыгыч оператив һәм башка хезмәтләр белән үз вакытында оператив хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыра;

Система белән эшләгәндә барлыкка килгән техник төзексезлекләр турында Система операторына техник ярдәм күрсәтү хезмәте телефоны буенча яки техник ярдәм күрсәтү хезмәтенең электрон адресына төзексезлек хакында заявка җибәреп хәбәр итә;

ашыгыч хезмәтләргә һәм хезмәттәшлек итүдә катнашучыларга балаларны йөртә торган автобуслар катнашындагы гадәттән тыш хәлләр турында мәгълүмат җиткерә;

2) муниципальара маршрутлар автобусларын диспетчерлаштырганда:

функцияләрне тулысынча башкару өчен кирәкле күләмдә диспетчерлык составының эшен оештыра;

Системада реаль вакыт режимында муниципальара маршрутлар автобусларын диспетчерлаштыруны әлеге төр хезмәтләр күрсәтүгә финанслау лимитлары кысаларында оештыра;

Системадан алынган мәгълүматлар нигезендә муниципальара маршрутлар автобусларын йөртүчеләрнең тизлек режимын, расланган хәрәкәт расписание һәм маршрутын саклавын һәм бозуларга үз вакытында чаралар күрүен тикшерүдә тота;

транспорт чарасы кабинасы белән – тавышлы элемтә, шулай ук йөртүче белән телефон элемтәсе аша муниципальара маршрутлар автобуслары йөртүчеләре белән үзара бәйләнештә торуны оештыра;

йөртүчеләрнең җитәкчеләре, шулай ук муниципальара маршрутлар автобусларының йөртүләрен оештыру өчен җаваплы затлар белән телефон элемтәсе аша үзара бәйләнештә торуны оештыра;

Системага муниципальара маршрутлар автобуслары хәрәкәте расписаниеләрен, аларның маршрутларын һәм Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгыннан алынган башка мәгълүматны кертүне тәэмин итә;

транспорт белән идарә итү буенча нәтиҗәле эш оештыру өчен кирәкле белешмә мәгълүматлар базасын төзи (автобуслар йөртүчеләр, транспорт чарасын линиягә чыгару өчен җаваплы затлар, йөртүчеләрнең җитәкчеләре, йөртүчеләрнең диспетчерлык хезмәтләре, муниципальара маршрутлар автобусларында, транспорт дислокациясе урыннарында куелган абонент терминалларына техник хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыра торган оешмалар хакында элемтә өчен мәгълүмат һ.б.);

сменадагы эш һәм хәлләр турында оператив белешмәләр һәм рапортлар төзи, шулай ук йөртү куркынычсызлыгын оештыруда һәм башкарыла торган эш нәтиҗәлелеген бәяләүдә катнаша торган хезмәттәшлек итүдә катнашучылар өчен кирәкле хисаплылылык әзерли;

йөртүчеләрдән һәм муниципальара маршрутлар автобуслары йөртүләрен оештыруда катнаша торган башка затлардан шалтыратулар кабул итү буенча тәүлек буе эшли торган «кайнар линия» оештыра;

электрон почта аша хезмәттәшлек итүдә катнашучылардан муниципальара маршрутлар автобуслары турында мәгълүматлар, хәрәкәт маршрутларында һәм расписаниеләрендә барлыкка килгән үзгәрешләр хакында һәм элемтә өчен мәгълүматлар кабул итүне оештыра

муниципальара маршрутлар автобуслары катнашында гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракларда, әлеге Нигезләмәнең 4 бүлегендә күздә тотылган тәртиптә ашыгыч хезмәтләр белән үз вакытында оператив хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыра;

Система белән эшләгәндә барлыкка килгән техник төзексезлекләр турында Система операторына техник ярдәм күрсәтү хезмәте телефоны буенча яки техник ярдәм күрсәтү хезмәтенең электрон адресына төзексезлек хакында заявка җибәреп хәбәр итә;

хезмәттәшлек итүдә катнашучыларга һәм ашыгыч хезмәтләргә муниципальара маршрутлар автобуслары катнашындагы гадәттән тыш хәлләр турында мәгълүмат җиткерә.

## 3. Муниципальара маршрутлар автобусларын һәм балаларны йөртә торган автобусларны Системага тоташтыру, автобуслар турындагы мәгълүматны Системадан алу

3.1. Балаларны йөртә торган автобусларны Системага тоташтыру өчен:

җирле үзидарә органы балаларны йөртә торган автобусны Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS системасы навигация сигналлары кулланылып эшли торган, коммерция максатларында ташулар өчен файдаланыла торган M категорияле һәм куркыныч йөкләрне ташу өчен файдаланыла торган N категорияле транспорт чараларына куелырга тиеш булган навигация чараларына таләпләрне раслау турында» 2012 ел, 31 июль, 285 нче боерыгына теркәлгән 3 нче кушымтага туры килә торган абонент терминалы һәм йөртүче кабинасы белән тавышлы элемтә аппаратурасы комплекты белән җиһазландыра;

җирле үзидарә органы әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада күрсәтелгән форма буенча балаларны йөртә торган автобусны Системага тоташтыру өчен гариза белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мөрәҗәгать итә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы гаризаны rnic@tatar.ru электрон адресына сорату җибәрү юлы белән Системага абонент терминалының id-ын кертү өчен Система операторына һәм балаларны йөртә торган автобус хакында мәгълүматны җирле үзидарә органнарыннан мөрәҗәгать килгәннән соң 24 сәгатьтән артмаган вакыт эчендә Системага кертү өчен диспетчерлык үзәгенә җибәрә;

җирле үзидарә органы Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS системасы навигация сигналлары кулланылып

эшли торган, коммерция максатларында ташулар өчен файдаланыла торган M категорияле һәм куркыныч йөкләрне ташу өчен файдаланыла торган N категорияле транспорт чараларына куелырга тиеш булган навигация чараларына таләпләрне раслау турында» 2012 ел, 31 июль, 285 нче боерыгы нигезендә абонент терминалындагы мониторинг мәгълүматын ip: 85.233.78.4:8087 серверына җибәрүне тәэмин итә;

Система операторы Системага мәгълүматлар кертүне, тоташтыруны һәм күрсәтелгән абонент терминалының id-ыннан мәгълүматлар трансляциясен (ретрансляциясен) раслый һәм Системага яңа абонент терминалын тоташтыру турында ике көн эчендә диспетчерлык үзәгенә хәбәр итә. Абонент терминалының id-ы кабатланган очракта җирле үзидарә органына абонент терминалы id-ын бер эш көне эчендә алыштырырга тәкъдим ителә;

диспетчерлык үзәге балаларны йөртә торган автобус турындагы мәгълүматны, күрсәтелгән абонент терминалы id-ына беркетеп, хезмәттәшлек итүдә катнашучылардан мөрәҗәгать алганнан соң 24 сәгатьтән артмаган вакыт эчендә Системага кертә.

3.2. Муниципальара маршрутлар автобусларын Системага тоташтыру өчен:

йөртүче муниципальара маршрут автобусын Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS системасы навигация сигналлары кулланылып эшли торган, коммерция максатларында ташулар өчен файдаланыла торган M категорияле һәм куркыныч йөкләрне ташу өчен файдаланыла торган N категорияле транспорт чараларына куелырга тиеш булган навигация чараларына таләпләрне раслау турында» 2012 ел, 31 июль, 285 нче боерыгына теркәлгән 3 нче кушымтага туры килә торган абонент терминалы һәм йөртүче кабинасы белән тавышлы элемтә аппаратурасы комплекты белән җиһазландыра;

йөртүче әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада күрсәтелгән форма буенча муниципальара маршрут автобусын Системага тоташтыру өчен гариза белән Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына мөрәҗәгать итә;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы гаризаны rnic@tatar.ru электрон адресына сорату җибәрү юлы белән Системага абонент терминалының id-ын кертү өчен Система операторына һәм муниципальара маршрутлар автобусы хакында мәгълүматны йөртүчедән мөрәҗәгать килгәннән соң 24 сәгатьтән артмаган вакыт эчендә Системага кертү өчен диспетчерлык үзәгенә җибәрә;

йөртүче Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS системасы навигация сигналлары кулланылып эшли торган, коммерция максатларында ташулар өчен файдаланыла торган M категорияле һәм куркыныч йөкләрне ташу өчен файдаланыла торган N категорияле транспорт чараларына куелырга тиеш булган навигация чараларына таләпләрне раслау турында» 2012 ел, 31 июль, 285 нче боерыгы нигезендә мониторинг мәгълүматын ip: 85.233.78.4:8087 серверына җибәрүне тәэмин итә;

Система операторы Системага мәгълүматлар кертүне, тоташтыруны һәм күрсәтелгән абонент терминалының id-ыннан мәгълүматлар трансляциясен (ретрансляциясен) раслый һәм Системага яңа абонент терминалын тоташтыру турында ике көн эчендә диспетчерлык үзәгенә хәбәр итә. Абонент терминалының id-ы

кабатланган очракта йөртүчегә абонент терминалы id-ын бер эш көне эчендә алыштырырга тәкъдим ителә;

диспетчерлык үзәге муниципальара маршрут автобусы турындагы мәгълүматны, күрсәтелгән абонент терминалы id-ына беркетеп, хезмәттәшлек итүдә катнашучылардан мөрәҗәгать алганнан соң 24 сәгатьтән артмаган вакыт эчендә Системага кертә.

3.3. Балаларны йөртә торган автобуслар турындагы мәгълүматны Системадан алу өчен:

җирле үзидарә органы әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада күрсәтелгән форма буенча балаларны йөртә торган автобус турында мәгълүматны Системадан алу өчен гариза белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мөрәҗәгать итә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы гаризаны rnic@tatar.ru электрон адресына сорату җибәрү юлы белән Системадан абонент терминалының id-ын алу өчен Система операторына һәм балаларны йөртә торган автобус хакында мәгълүматны җирле үзидарә органнарыннан мөрәҗәгать килгәннән соң 24 сәгатьтән артмаган вакыт эчендә Системадан алу өчен диспетчерлык үзәгенә җибәрә;

Система операторы Системадан гаризада күрсәтелгән абонент терминалының id-ын алуны раслый һәм алган мизгелдән соң ике сәгатьтән артмаган вакыт эчендә диспетчерлык үзәгенә хәбәр итә;

диспетчерлык үзәге балаларны йөртә торган автобус турындагы мәгълүматны хезмәттәшлек итүдә катнашучылардан мөрәҗәгать алганнан соң 24 сәгатьтән артмаган вакыт эчендә Системадан ала.

3.4. Муниципальара маршрутлар автобуслары турындагы мәгълүматны Системадан алу өчен:

йөртүче әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада күрсәтелгән форма буенча муниципальара маршрут автобусы турында мәгълүматны Системадан алу өчен гариза белән Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына мөрәҗәгать итә;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы гаризаны rnic@tatar.ru электрон адресына сорату җибәрү юлы белән Системадан абонент терминалының id-ын алу өчен Система операторына һәм муниципальара маршрут автобусы хакында мәгълүматны йөртүчедән мөрәҗәгать килгәннән соң 24 сәгатьтән артмаган вакыт эчендә Системадан алу өчен диспетчерлык үзәгенә җибәрә;

Система операторы Системадан гаризада күрсәтелгән абонент терминалының id-ын алуны раслый һәм алган мизгелдән соң ике сәгатьтән артмаган вакыт эчендә диспетчерлык үзәгенә хәбәр итә;

диспетчерлык үзәге муниципальара маршрут автобусы турындагы мәгълүматны хезмәттәшлек итүдә катнашучылардан мөрәҗәгать алганнан соң 24 сәгатьтән артмаган вакыт эчендә Системадан ала.

## 4. Штаттан тыш хәлләр килеп чыкканда хезмәттәшлек итү

4.1. Пассажирларны транспортта йөрткәндә барлыкка килә торган штаттан тыш хәлләр классификациясе:

1) 1 куркыныч категориясе:

автобусның техник төзексезлек буенча туктавы;

автобусның метеошартлар буенча туктавы;

автобусның юл шартлары буенча туктавы;

билгеләнгән хәрәкәт маршрутыннан тайпылу;

тизлек режимының системалы яки озак вакытка бозылуы;

2) 2 куркыныч категориясе:

зыян күрүчеләр булмаган юл-транспорт һәлакәте;

3) 3 куркыныч категориясе:

зыян күрүчеләр булган юл-транспорт һәлакәте;

автобусның яныпп китүе;

4) 4 куркыныч категориясе:

хокукка каршы гамәлләр (террорчылык акты, басып алу, һөҗүм итү куркынычы).

4.2. Абонент терминалы белән җиһазландырылган һәм Системага тоташтырылган автобусны йөртүче:

1) теләсә кайсы куркыныч категориясенә караган штаттан тыш хәлләр килеп чыкканда:

кисәтү төймәсенә (диспетчерны чакыру төймәсе) баса һәм диспетчерлык үзәге диспетчырының транспорт чарасы кабинасына шалтыратуын көтә;

диспетчерлык үзәге хезмәткәренә куркыныч туу турында хәбәр итә, вакыйга вакытын һәм урынын, сәбәбен, зыян күрүчеләр санын, пассажирларның җәрәхәтләре дәрәҗәсен, автобус хәлен, һава торышын, юл шартларын күрсәтә;

2) 2 – 4 куркыныч категорияләренә караган штаттан тыш хәлләр килеп чыкканда, кисәтү төймәсенә басуга бәйсез рәвештә «112» номерына шалтырата, «112» хезмәте диспетчерына куркыныч туу турында хәбәр итә, вакыйга вакытын һәм урынын, сәбәбен, зыян күрүчеләр санын, пассажирларның җәрәхәтләре дәрәҗәсен, автобус хәлен, һава торышын, юл шартларын күрсәтә;

3) 1 куркыныч категориясенә караган штаттан тыш хәлләр килеп чыкканда, диспетчерлык үзәгенә кисәтү төймәсеннән элемтәгә керәп булмаса, диспетчерлык үзәгенең «кайнар линия» номерына яисә автобус хуҗасы булган йөртүченең диспетчерлык үзәгенә шалтырата һәм туктауның сәбәбе, урыны, пассажирлар булу-булмавы, аларның саны, метеошартлар һәм юл шартлары турында мәгълүмат җиткерә.

4.3. Диспетчерлык үзәге хезмәткәре:

1) теләсә кайсы куркыныч категориясенә караган штаттан тыш хәлләр килеп чыкканда:

Системаның web-интерфейсына кисәтү төймәсеннән сигнал килгән очракта, Системаның web-интерфейсыннан автобус йөртүче кабинасына шалтырата;

автобус йөртүчедән штаттан тыш хәл килеп чыгу турында хәбәр ала;

2) 2 – 4 куркыныч категорияләренә караган штаттан тыш хәлләр килеп чыкканда, бөтен килгән мәгълүматны Системаның вакыйгалар карточкасына кертә

һәм алга таба хәл итү өчен Система эчендә аны «112» хезмәте диспетчерына җибәрә, йөртүче белән элемтәдә тору һәм хезмәтләрне чакыртуны тизәйтү юлы белән вакыйга булган урынга ашыгыч оператив хезмәтләр килүен тикшерүдә тота;

3) 1 куркыныч категориясенә караган штаттан тыш хәлләр килеп чыкканда:

килгән мәгълүматны язып ала, пассажирларны башка транспорт чарасына күчереп утырту кирәк булу-булмавы турында тәгаенли, автобус аныкы булган автотранспорт предприятиесе диспетчерына һәм Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының оператив кизү торучысына килеп чыккан хәл турында хәбәр итә, йөртүче һәм башка хезмәттәшлек итүдә катнашучылар белән телефон элемтәсендә тору юлы белән вакыйганы хәл итүне тикшерүдә тота;

автобус хәрәкәт маршрутыннан һәм расписаниесеннән тайпылып хәрәкәт иткән һәм туктаган яки тукталыш өчен каралмаган урында туктаган, системалы яки озак вакытка тизлек режимын арттырган очракта, шулай ук линиядә 5 минуттан күбрәк булган транспорт чарасы белән элемтә булмаган очракларда, йөртүче кабинасына шалтырата һәм тайпылу/туктау һәм тизлек режимын бозу сәбәпләрен сорый;

йөртүче кабинасы белән элемтәгә кереп булмаган очракта, йөртүченең кесә телефонына шалтырата; кесә телефонына шалтыратып булмаса, җирле үзидарә органнарында балаларны йөртүне оештыру өчен җаваплы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешма, яки өстәмә белем бирү оешмасы, яки физкультура-спорт оешмасы җитәкчесенә һәм йөртүченең диспетчерлык үзәгенә, шулай ук Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең кизү частенә килеп чыккан хәл турында хәбәр итә.

4.4. «112» бердәм диспетчерлык хезмәте хезмәткәре, 2 – 4 куркыныч категорияләренә караган штаттан тыш хәлләр килеп чыккан очракта, Система эчендә диспетчерлык үзәге хезмәткәреннән килгән вакыйга карточкасын яки «112» номерына автобус йөртүченең шалтыратуын эшкәртә һәм «112» бердәм диспетчерлык хезмәтенең расланган эш регламенты нигезендә хәл итүне оештыра.

Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыру бердәм системасы турындагы нигезләмәгә кушымта

Форма

______________________________________

(министрлык яки

______________________________________

Система операторы исеме)

**гариза**

______________________________________________________________

(оешма исеме)

транспорт чарасын «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтыруыгызны («ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан транспорт чарасы турындагы мәгълүматны алуыгызны) сорыйм

| Оешма турында мәгълүмат | |
|---|---|
| Оешма исеме (тулы) | |
| Оешма исеме (кыскартылган) | |
| Адресы (юридик һәм факттагы) | |
| Төп дәүләт теркәү саны (ОГРН) | |
| Шәхси тәңгәлләштерү саны (ИНН) | |
| Җитәкченең Ф.И.Ат.и. | |
| Телефон | |
| Факс | |
| Электрон почта адресы | |

«ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырырга («ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан чыгарырга) планлаштырыла торган транспорт чаралары турында

**мәгълүматлар**

| Дәүләт номеры | Трекер төре | Трекер-ның ID | Моделе | Төре | Профиле | Катего-риясе | Оешма | Хезмәт күрсәтә торган оешма | Милекче-оешма | Гараж номеры | Төсе | Чыга-рылган елы | VIN | ПТС | 1 SIM карта | 2 SIM карта |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | | | | |

«____»________201_ _ел Җитәкче имзасы

М.У.

F:\KARAR\2016\352.doc